**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 5 декабрендәге 5035 номерлы карары**

# Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру турында

Россия Федерациясе шәһәрләре арасында туризм өлкәсендә муниципальара хезмәттәшлекне үстерү, шулай ук туристлык индустриясе хезмәткәрләренең хезмәт дәрәҗәсен күтәрү һәм аларның үз эшчәнлекләрендә иң югары нәтиҗәләргә ирешүенә этәргеч бирү максатыннан **карар бирәм**:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивале турында нигезләмә (1 номерлы кушымта);

1.2. Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру буенча экспертлар советы составы (2 номерлы кушымта).

2. «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Д.А.Санникова) Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален оештыруга һәм уздыруга вәкаләт бирергә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына (Б.Р.Алиев) чараны тәэмин итүгә чыгымнар сметасын 3 313,2 мең сум күләмендә, шул исәптән 856,317 мең сум күләмендә – 2024 елга «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе сметасы акчалары кысаларында, 2 456,883 мең сум күләмендә өстәмә финанслау чыганаклары хисабына расларга һәм бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә (И.Р.Мөхәммәтшин) «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален гамәлгә ашыруга ассигнованиеләрне муниципаль милектәге акцияләрне сатудан алынган керемнәрнең калган өлеше хисабына 2 456, 883 мең сумга арттырырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 5 декабрендәге
5035 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивале турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален (алга таба – Фестиваль) уздыру тәртибен җайга сала, Фестивальнең максатларын һәм бурычларын, оештыру, үткәрү вакытын һәм анда катнашу шартларын, катнашу өчен гаризалар бирү тәртибен, бәйге нигезендә сайлап алу һәм Фестивальдә җиңүчеләрне бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Фестивальне оештыручы – Идел буе шәһәрләре ассоциациясе ярдәме белән «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Фестивальне оештыручы).

1.3. Фестивальдә катнашу өчен Фестивальдә катнаша торган шәһәрләр Фестивальне оештыручыга Фестивальдә катнашу мәсьәләсе буенча уңай карар кабул ителү турында мәгълүмат юлларга тиеш.

1.4. Фестивальне оештыручы тарафыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1.4.1. Фестивальдә катнашучыларның барысы өчен дә тигез шартлар;

1.4.2. Фестивальне үткәрүдә ачыклык;

1.4.3. Фестиваль нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны аларны рәсми рәвештә игълан итү көненнән иртәрәк хәбәр итүне булдырмау;

1.4.4. Фестивальдә җиңгән һәм призлы урыннар яулаган катнашучыларга бүләкләр тапшыру.

1.5. Фестивальне үткәрүне тәэмин итү өчен Фестивальне оештыручы тарафыннан түбәндәгеләр төзелә:

1.5.1. Бәяләү коллегиясе – Фестивальдә катнашучылар тарафыннан сайлап алу этабы биремнәренең үтәлешен һәм Фестивальнең төбәкара этабына узган катнашучыларның һөнәри осталыкларын бәяләүне гамәлгә ашыра торган орган;

1.5.2. Бәяләү коллегиясенең апелляция комиссиясе – сайлап алу этабында Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итә торган, шулай ук Фестивальнең сайлап алу этабында катнашучыларның шикаятьләрен кабул итүне һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыра торган орган;

1.5.3. Финал этабы жюрие – финал этабында Фестивальдә катнашучыларның һөнәри осталыгын бәяләүне гамәлгә ашыра һәм Фестиваль номинацияләрендә җиңүчеләрне билгели торган орган;

1.5.4. Экспертлар советы – Фестивальнең төбәкара этабы нәтиҗәләренең объективлыгын тәэмин итә торган орган.

1.6. Фестивальнең бәяләү коллегиясе, экспертлар советы, бәяләү коллегиясенең апелляция комиссиясе һәм финал этабы жюрие составын формалаштырганда Фестивальне оештыручы Идел буе шәһәрләре ассоциациясенә керүче шәһәрләрнең вәкилләре фикеренә таяна.

1.7. Фестивальнең бәяләү коллегиясе, экспертлар советы, бәяләү коллегиясенең апелляция комиссиясе һәм финал этабы жюрие, карарлар кабул иткәндә, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.8. Фестивальне оештыручы Фестивальнең бәяләү коллегиясе, экспертлар советы, бәяләү коллегиясенең апелляция комиссиясе һәм финал этабы жюрие составы турындагы мәгълүматны, Фестивальнең һәр этабын уздыру датасына кадәр өч календарь көннән соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Идел буе шәһәрләре ассоциациясе сайтында (www.agpsamara.ru) урнаштыра.

## II. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Фестивальнең төп максатлары – Россия Федерациясенең Фестивальдә катнашу турында карар кабул иткән шәһәрләрендә туризмны үстерү өчен шартлар булдыру, туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү.

2.2. Фестивальнең бурычлары:

- Россия Федерациясе шәһәрләренең туристлык, ресторан һәм кунакханә ресурсларын популярлаштыру;
- туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүгә һәм конкуренциягә сәләтен арттыруга ярдәм итү;
- әлеге өлкә хезмәткәрләренең һөнәри белем, осталык һәм күнекмәләр дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук иҗади башлангычларын үстерү;

- җәмәгатьчелектә туристлык һәм кунакчыллык индустриясе һөнәрләренә карата уңай фикер формалаштыру;
- Россия шәһәрләренең туристларны җәлеп итүчәнлеген арттыру.

## III. Фестиваль номинацияләре

3.1. Фестиваль ун төп индивидуаль номинация буенча уздырыла:

- «Иң яхшы портье»;
- «Иң яхшы җыештыручы»;
- «Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер»;
- «Ресторанның иң яхшы менеджеры»;
- «Иң яхшы официант»;
- «Иң яхшы бармен»;
- «Иң яхшы пешекче»;
- «Иң яхшы кондитер»;
- «Иң яхшы сити-блогер»;
- «Кунакчыллык өлкәсендә яшь йолдыз. Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер».

3.2. Фестивальне оештыручы тарафыннан туризм өлкәсе предприятиеләре өчен «Тотрыклы туризм өлкәсендә Казан шәһәренең иң яхшы предприятиесе» махсус номинациясе булдырды.

3.3. Фестивальне оештыручы, гаризалар кабул итү башланганчы, экспертлар советы карары белән өстәмә номинацияләр формалаштыра. Шулай ук Фестивальне оештыручы, әлеге номинацияләр буенча катнашучылар тарафыннан бирелгән гаризалар саны 5 данәдән кимрәк булган очракта, экспертлар советы карары нигезендә Фестивальнең бер яки берничә номинациясен төшереп калдыра.

## IV. Фестивальдә катнашучылар

4.1. Фестивальдә катнашучылар – Фестивальдә тиешле номинацияләрдә катнашуга гариза-анкета тапшырган физик яки юридик затлар.

4.2. Фестивальнең төп номинацияләрендә катнашучылар – Фестивальдә катнашучы шәһәрләрнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләреннән гариза-анкета тапшырган хезмәткәрләр.

4.3. Фестивальдә төп номинацияләр буенча катнашучылар туризм һәм (яки) кунакчыллык өлкәсендә кимендә алты ай эш стажына ия булырга һәм

хәзерге вакытта билгеләнгән номинациягә («Иң яхшы сити-блогер» номинациясеннән тыш) туры килә торган белгечлек буенча эшләргә (шул исәптән берьюлы ике эштә һәм гражданлык-хокук килешүе буенча) тиеш.

4.4. Шәһәрләрнең туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре Фестивальнең төп номинацияләрендә катнашу өчен һәр номинациядә өчтән артык булмаган санда катнашучы тәкъдим итә ала.

4.5. Фестивальнең «Яшь йолдыз. Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясендә катнашучылар – гариза-анкета тапшырган югары уку йортлары студентлары һәм урта һөнәри белем бирүче уку йортлары укучылары.

4.6. Фестивальнең «Тотрыклы туризм өлкәсендә Казан шәһәренең иң яхшы предприятиесе» махсус номинациясендә катнашучылар – Казан шәһәренең үз эшчәнлекләрендә тотрыклы үсеш принцибына таяна торган, гариза-анкета тапшырган кунакчыллык һәм туризм өлкәсе предприятиеләре (күмәк урнаштыру чаралары, җәмәгать туклануы учреждениеләре).

4.7. Фестивальне оештыручылар һәм бәяләү коллегиясе әгъзалары Фестивальдә катнаша алмый.

4.8. Узган елгы Фестивальдә җиңгән физик затлар Фестивальдә элек җиңү яулаган номинациядә катнаша алмый.

## V. Фестиваль этаплары

5.1. Фестиваль ике этапта уздырыла: сайлап алу этабы (беренче тур) һәм төбәкара этап (икенче тур, финал).

5.2. Сайлап алу этабының тәгәлләнү вакыты – 2025 елның 28 гыйнвары (бәяләү коллегиясе карарын әзерләүне һәм чыгаруны исәпкә алып). Сайлап алу этабы түбәндәге чараларны үз эченә ала:

- бәяләү коллегиясен төзү;
- Фестивальдә катнашучылардан гариза-анкеталар кабул итү;
- Фестивальдә катнашучыларга «Өй эше» сайлап алу этабы биремен юллау һәм Фестивальдә катнашучылардан материаллар кабул итү;
- Фестивальнең сайлап алу этабы биремен бәяләү нәтиҗәләрен һәм Фестивальнең төбәкара этабына узган катнашучыларны билгеләү.

5.3. Төбәкара этап 2025 елның 5 февраленнән 21 февраленә кадәр уздырыла һәм түбәндәге чараларны үз эченә ала:

- сайлап алу этабында җиңүчеләр турында мәгълүмат җыю;
- жюри составын формалаштыру;

- экспертлар советын формалаштыру;

- Казан шәһәрендә конкурс чараларын үткәрү;

- Фестивальнең нәтиҗәләрен ачыклау һәм җиңүчеләрен бүләкләү.

5.4. Фестивальнең бәяләү коллегиясе һәм экспертлар советы әгъзаларына гаризалар кабул итү стадиясендә, шулай ук Фестивальнең сайлап алу этабын уздыру чорында туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясенә караган башка предприятиеләрдән катнашучыларны җәлеп итү белән шөгыльләнү тыела.

## VI. Фестивальнең беренче турын (сайлап алу этабын) әзерләү һәм уздыру

6.1. Сайлап алу этабын уздыру өчен Фестивальне оештыручы тарафыннан Фестиваль уздыру турында мәгълүмат басылып чыккан көнгә кадәр Фестивальне оештыручы, Идел буе шәһәрләре ассоциациясе һәм туристлык, ресторан һәм кунакханә бизнесы, иҗтимагый, фәнни һәм уку-укыту оешмалары вәкилләреннән торган бәяләү коллегиясе төзелә.

6.2. Бәяләү коллегиясе төзелгәннән соң, Фестивальдә катнаша торган шәһәрләрнең җирле үзидарә органнары Фестиваль турында мәгълүматны, гаризалар кабул итү өчен гариза-анкета формасын шәһәрнең тиешле оешмаларына, предприятиеләренә һәм массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрә.

6.3. Фестивальдә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән номинацияләрдә катнашу өчен гариза-анкета әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта белән билгеләнгән форма буенча тутырыла һәм әлеге Нигезләмәнең 6.3.1, 6.3.2 пунктларында күрсәтелгән документлар белән бергә гариза-анкетаныңтүбәндәге сылтама буенча урнаштырылган электрон формасын тутыру юлы белән электрон рәвештә җибәрелә: https://forms.yandex.ru/cloud/66067543c417f32779f1d4a3/.

6.3.1. Фестивальдә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән номинацияләрдә катнашу өчен гариза-анкетага түбәндәге документлар (сканерланган jpeg форматындагы күчермәләр) теркәлә («Иң яхшы сити-блогер» номинациясеннән тыш):

- кунакчыллык өлкәсенә караган оешмалардагы эш урыныннан белешмә;
- белем алу турында диплом күчермәсе яки уку урыныннан белешмә;
- хезмәт кенәгәсенең оешма мөһере белән расланган күчермәсе;

- һөнәри керемгә салым түләүче физик зат (үзмәшгуль) сыйфатында номинациягә туры килә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырган очракта – физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую турында белешмә (КНД 1122035 формасы буенча).

6.3.2. Катнашучы теләге буенча гариза-анкетага грамоталар, дипломнар, рәхмәт хатлары, бүләкләр турындагы таныклыклар, бәяләмәләр (булган очракта) күчермәләре, шул исәптән һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашу турында документ күчермәләре теркәлергә мөмкин.

6.4. Фестивальдә әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән номинациядә катнашу өчен гариза-анкета әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта белән билгеләнгән форма буенча тутырыла һәм әлеге пунктта күрсәтелгән документлар белән бергә гариза-анкетаның түбәндәге сылтама буенча урнаштырылган электрон формасын тутыру юлы белән электрон рәвештә җибәрелә: https://forms.yandex.ru/u/672601dd068ff016f89168d3/.

Фестивальдә әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән номинациядә катнашу өчен гариза-анкетага түбәндәге документлар (сканерланган jpeg форматындагы күчермәләр) теркәлә:

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан электрон өземтә;
- юридик затны яки шәхси эшмәкәрне теркәү турында таныклык;
- салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы үтәлгән булу турында электрон белешмә;
- компания катнашырга ният белдергән тематик юнәлешләр буенча программалар (һәр юнәлештә бер генә программа тәкъдим ителергә мөмкин, компания сайлаган юнәлешләр саны чикләнми).

6.5. Фестивальнең барлык номинацияләре буенча гариза-анкеталар Фестивальне оештыручы тарафыннан 2025 елның 10 гыйнварына кадәр кабул ителә.

6.6. 2025 елның 13 гыйнварына кадәр Фестивальне оештыручы Фестивальдә катнашучыларга «Өй эше» сайлап алу этабы биремен һәм аны бәяләү критерийларын юллый.

6.7. Сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары Фестивальнең һәр номинациясе өчен билгеләнә һәм әлеге Нигезләмәгә 3-13 номерлы кушымталарда китерелә.

6.8. Фестивальдә катнашучы 2025 елның 20 гыйнварына кадәр «Яндекс.Диск» файллар хостингында (disk.yandex.ru) «Өй эше» сайлап алу этабы

биремнәрен үтәү буенча материаллар урнаштырырга тиеш. Фестивальдә катнашучылар «Өй эше» сайлап алу этабы биремнәрен үтәү буенча урнаштырылган материалларына сылтамаларны zv.g@tatar.ru электрон почта адресына җибәрәләр.

6.9. Фестивальне оештыручы 2025 елның 20 гыйнварына кадәр Фестивальдә катнашучылардан алар тарафыннан «Өй эше» сайлап алу этабы биремнәренең үтәлеше турында мәгълүмат җыя һәм аны бәяләү коллегиясенә тапшыра.

6.10. Фестивальдә катнашуга гариза-анкеталар кабул итү тәмамланганнан соң ун эш көненнән дә соңга калмыйча уздырылырга тиешле утырышта бәяләү коллегиясе гариза-анкеталарның әлеге Нигезләмәнең 6.3, 6.4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм Фестивальдә катнашуга дәгъва кылучыларны сайлап алу этабында катнашуга кертү турында карар кабул итә.

6.11. Фестивальдә катнашуга дәгъва кылучының гариза-анкетасы әлеге Нигезләмәнең 6.3, 6.4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, бәяләү коллегиясе Фестивальдә катнашуга дәгъва кылучыны Фестивальнең сайлап алу этабында катнашуга кертмәү турында карар кабул итә һәм тиешле карар чыгарылган көннән башлап өч календарь көн эчендә аңа бу хакта хәбәр итә.

6.12. 2025 елның 22 гыйнварыннан 27 гыйнварына кадәрге чорда бәяләү коллегиясе:

- сайлап алу этабындагы биремнең Фестивальдә катнашучылар тарафыннан үтәлешен һәм аларның һөнәри осталыгын бәяли;
- Фестивальнең төбәкара этабына узган катнашучыларын билгели.

6.13. Бәяләү коллегиясе утырышында аның әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы булып санала.

6.14. Бәяләү коллегиясе карары, 2025 елның 28 гыйнварыннан да соңга калмыйча, беркетмә белән рәсмиләштерелә.

6.15. Фестивальнең сайлап алу этабы тәмамланганнан соң өч көн эчендә бәяләү коллегиясе җиңүчеләр турында мәгълүматны Фестивальне оештыручыга юллый.

6.16. Фестивальдә «Өй эше» сайлап алу этабы биремен бәяләү нәтиҗәләре буенча үз номинацияләрендә иң күп балл җыйган (әлеге Нигезләмәгә 3-11 номерлы кушымталар нигезендә) катнашучылар сайлап алу этабының җиңүчеләре булып таныла.

6.17. Фестивальнең сайлап алу этабында җиңүчене билгеләгәндә бәяләү коллегиясе тарафыннан Фестивальнең берничә катнашучысына тигез санда баллар бирелсә, иң күп балл җыйган барлык катнашучылар сайлап алу этабының җиңүчеләре дип танылa.

6.18. Фестивальдә катнашучыны бәяләгәндә һәм әлеге катнашучыны Фестивальнең сайлап алу этабы җиңүчесе дип тану турында карар чыгарганда бәяләү коллегиясе әгъзасының яки әгъзаларының шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, бәяләү коллегиясе әгъзасы бу хакта Фестивальне оештыручыга кичекмәстән хәбәр итәргә һәм бәяләү коллегиясе әгъзасы вәкаләтләрен үз өстеннән төшерергә тиеш.

6.19. Биремне бәяләү нәтиҗәләре, бәяләү коллегиясенең җиңүчене билгеләү турындагы карары белән килешмәгән очракта, Фестивальдә катнашучы бәяләү коллегиясенең апелляция комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, сайлап алу этабы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, өч календарь көн эчендә бирелә.

## VII. Фестивальнең төбәкара (финал) этабын әзерләү һәм уздыру

7.1. Фестивальне оештыручы Фестивальнең финал этабындагы жюри составын Фестивальнең финал этабында катнаша торган шәһәрләрнең җирле үзидарә органнары һәм Идел буе шәһәрләре ассоциациясе тәкъдимнәре нигезендә раслый.

7.2. Фестивальнең финал этабындагы жюри кунакчыллык индустриясе өлкәләрендәге экспертлардан, Фестивальдә катнаша торган шәһәрләр вәкилләреннән һәм башка компетентлы затлардан торырга тиеш.

7.3. Аерым номинацияләр буенча жюри әгъзалары саны – кимендә өч кеше.

7.4. Фестивальнең финал этабында чит шәһәрләрдән килгән жюри әгъзалары өчен төбәкара этап уздырыла торган шәһәргә бару, анда яшәү һәм кайту белән бәйле чыгымнар Фестивальне оештыручыга йөкләнә.

7.5. Фестивальне уздыру максатыннан Фестивальнең финал этабындагы жюри әгъзаларыннан, шулай ук Фестивальдә катнаша торган шәһәрләрнең муниципаль берәмлекләре вазифаи затларыннан һәм башка затлардан торган экспертлар советы төзелә.

7.6. Экспертлар советы Фестивальнең төбәкара этабы нәтиҗәләренең объективлыгын тәэмин итү максатыннан раслана.

7.7. Фестивальнең төбәкара этабын уздырганда Фестивальне оештыручының төп функцияләре:

- жюри һәм экспертлар советы составын формалаштыру;
- Фестивальнең төбәкара этабына узган катнашучылар турында мәгълүмат җыю;
- Фестивальнең аерым номинацияләре буенча конкурс чараларын уздыру графигын һәм урынын раслау;
- конкурс чараларын әзерләү һәм уздыру.

7.8. 2025 елның 30 гыйнварына кадәр Фестивальне оештыручы, Фестивальнең сайлап алу этабында катнашып, төбәкара этапка узучыларга Фестивальнең төбәкара этабын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат җиткерә. Фестивальнең төбәкара этабын уздыру өчен башка дата билгеләнгән очракта, Фестивальне оештыручы тарафыннан Фестивальдә катнашучыларга Фестивальнең төбәкара этабын уздыру датасы һәм урыны турында, төбәкара этапны уздыру көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча, электрон почта аша хәбәр ителә.

7.9. Фестивальнең төбәкара этабы 2025 елның 5 февраленнән 21 февраленә кадәр үткәрелә.

7.10. Фестивальнең финал этабында катнашучылар төбәкара этап уздырыла торган шәһәргә кадәр бару, анда яшәү һәм кайту белән бәйле чыгымнарны үзләре каплый.

## VIII. Конкурсны уздыру һәм җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

8.1. Фестивальдә катнашучыларның һөнәри осталык дәрәҗәсен Фестивальнең финал этабындагы жюри бәяли. Хөкемдарлык барышында шәхси кызыксыну очрагын булдырмау максатыннан номинациядә катнашучы һәр кеше буенча бәя коллегиаль рәвештә кабул ителә һәм, уртак фикер алышудан соң, бердәм ачык бәяләү кәгазенә куела.

8.2. Катнашучыларның һөнәри осталык дәрәҗәсен бәяләү Фестивальне оештыручы тарафыннан билгеләнә торган импровизацияләнгән эш урыннарында үткәрелә.

8.3. Фестиваль таләпләренә һәм шартларына туры килә торган катнашучыларны һәр номинация өчен экспертлар советы тарафыннан эшләнгән бәяләү кәгазьләре нигезендә жюри әгъзалары бәяли. Катнашу шартлары, бәяләү критерийлары Фестивальне оештыручы тарафыннан раслана һәм Фестивальнең гамәли өлеше башланырга җиде көн кала катнашучыларга җиткерелә.

Катнашучы рейтингы жюри әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар суммасына тигез була. Катнашучылар арасында баллар нәтиҗәсе тигезләшкән очракта, өстенлек грамоталар, дипломнар, рәхмәт хатлары, бүләкләү турындагы таныклыклар күчермәләрен тапшырган катнашучыга бирелә.

Жюри әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар суммасына түбәндәгеләр өстәлә:

- 1 балл – катнашучының Фестивальдә катнаша торган төбәк/шәһәр территориясендә һөнәри осталык бәйгесе җиңүчесе яки призеры дипломы булган очракта;
- 0,5 балл – катнашучының Фестивальдә катнаша торган төбәк/шәһәр территориясендә һөнәри осталык бәйгесендә катнашу турында грамотасы яки белешмәсе булган очракта.

8.4. Фестивальнең финал этабындагы жюри яки Фестивальне оештыручы тарафыннан Фестивальдә катнашучыларның һөнәри осталыгын бәяләү өчен «яшерен кунак» җәлеп итү юлы белән өстәмә бәя бирү турында карар кабул ителгән очракта, гомуми бәя импровизацияләнгән эш урынындагы бәяләүнең һәм «яшерен кунак» тарафыннан бирелгән бәянең уртача арифметик зурлыгы буларак билгеләнә.

8.5. Фестивальдә иң күп балл җыйган катнашучылар җиңүче дип таныла.

8.6. Фестивальнең финал этабындагы жюри карарлары анда катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Фестивальнең финал этабындагы жюри карары, аның әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашында кабул ителсә, тулы хокуклы дип санала.

8.7. Фестивальнең финал этабындагы жюри карарлары һәр номинация буенча тавыш бирү кәгазендә рәсмиләштерелә. Ул жюри әгъзалары тарафыннан имзалана һәм экспертлар советына тапшырыла, ә күчермәсе Фестивальне оештыручыга бирелә.

8.8. Финал этабындагы жюри карары экспертлар советы, аның чарада катнашкан әгъзаларының күпчелеге тарафыннан раслана, бу хакта беркетмә төзелә.

8.9. Биремне бәяләү нәтиҗәләре, төбәкара этаптагы жюри әгъзаларының җиңүчене билгеләү турында карары белән килешмәгән очракта, катнашучы Фестивальнең экспертлар советына апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, төбәкара этап нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, өч календарь көн эчендә бирелә.

8.10. Фестивальне оештыручы 2025 елның 28 февраленә кадәр Фестиваль нәтиҗәләрен Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында

(www.kzn.ru) һәм Идел буе шәһәрләре ассоциациясе сайтында (www.agpsamara.ru) урнаштыра.

## IX. Фестивальгә нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

9.1. Фестивальнең төбәкара этабы йомгаклары буенча катнашучыларга һәр номинациядә I, II, III урыннар бирелә.

9.2. Фестивальнең төбәкара этабында номинация буенча I урын яулаган җиңүчегә «Кунакчыллык йолдызы – 2024» дипломы, акчалата бүләк, кубок һәм башка истәлекле бүләкләр тапшырыла.

9.3. Фестивальнең һәр номинациясендә җиңүчеләргә 50 000 (илле мең) сум күләмендә акчалата бүләк бирелә.

9.3.1. Җиңүче физик затлар өчен бүләк суммасы физик затлар кеременә салымны тотып калып исәпләнгән һәм җиңүчеләргә түләү өчен ахыргы сумма булып тора.

9.3.2. Фестивальдә җиңүчеләргә бүләк акчасын түли торган оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 24 статьясы нигезендә салым агенты булып тора һәм отыш суммасының 13 проценты күләмендә физик затлар керемenә салына торган салымны түли.

9.3.3. Җиңүче юридик затлар яки шәхси эшмәкәрләр өчен бүләк суммасы салым салуның гомуми системасы кулланылган очракта салым түләүче тарафыннан түләнә торган табышка салымны исәпкә алмыйча һәм салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланганда түләнә торган салымны исәпкә алмыйча исәпләнгән.

9.4. Фестивальнең төбәкара этабында II һәм III урыннар яулаган катнашучыларга дипломнар һәм башка истәлекле бүләкләр тапшырыла.

9.5. Фестиваль җиңүчеләренә акчалата эквививаленттагы бүләк 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

9.6. Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы 2025 елның 21 февраленнән дә соңга калмыйча уздырылырга тиеш.

---

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивалендә катнашу өчен гариза-анкета**

Фотосурәт 3х4 см*

| | |
|---|---|
| 1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме* | |
| 2. Эш урыны, вазифасы (учреждениенең, оешманың тулы атамасы)* | |
| 3. Җенесе | |
| 4. Туу датасы (көне, ае, елы) | |
| 5. Туу урыны | |
| 6. Белеме (уку йортының тулы атамасы, тәмамлау елы, белгечлек) | |
| 7. Һөнәри конкурсларда катнашу турында мәгълүмат | |
| 8. Һөнәри бүләкләр, бүләкләнү датасы | |
| 9. Чит телләрне белү турында мәгълүмат (күрсәтергә) | |
| 10. Эш стажы (гомуми һәм тармактагы эш стажын күрсәтергә) | |
| 11. Элемтә өчен телефон номеры* | |
| 12. E-mail* | |

| | |
|---|---|
| 13. Өстәмә мәгълүмат (квалификация күтәрү, бүләкләр, рәхмәт хатлары, клиентларның һәм партнерларның бәяләмәләре (шул исәптән социаль челтәрләрдәге), проектларда катнашу, видеопрезентация һ.б.) | |

* Мәҗбүри күрсәтелә.

Әлеге гаризага түбәндәге документлар (яки аларның сканерланган jpeg форматындагы күчермәләре) теркәлә:

- кунакчыллык һәм туризм өлкәсенә караган оешмалардагы эш урыныннан белешмә;
- белем алу турында диплом күчермәсе/уку урыныннан белешмә;
- өстәмә белем алу, квалификация күтәрү, курслар, стажировкалар узу турында һәм башка документларның күчермәләре (булган очракта);
- хезмәт кенәгәсенең оешма мөһере белән расланган күчермәсе;
- башка материаллар (гариза бирүче теләге буенча).

Оешма җитәкчесе: ____________________ / ________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2024 елның «______» ______________

Мөһер урыны

**ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК**

Мин, ________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
____________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
__________________________________________________________________,
шәхесне раслаучы документ: ______________, сериясе: ______номеры: ________
бирү датасы «_____» __________ кем тарафыннан бирелгән
____________________________________________________________________
___________________________________________________________________,
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 11А йорт, 5Н бина) шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, атап әйткәндә, эш бирүчегә хәбәр ителгән тормышымдагы фактлар, вакыйгалар һәм хәлләр турындагы мәгълүмат белән 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 3 статьясында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм.

Мине Казан шәһәренең муниципаль бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү максатыннан, шулай ук Казан шәһәре бүләкләре белән бүләкләнгән затлар турында мәгълүматны саклау максатыннан, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә эшкәртүгә ризалык биргән шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән: паспорт турында мәгълүматларны, белем алу турында (уку йортының тулы атамасы, тәмамлау елы, белгечлек) мәгълүматларны, җенес, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем, махсус исем турында белешмәләрне, дәүләт бүләкләре (шул исәптән бүләкләү датасы) турында белешмәләрне, бүләкләүнең башка төрләре булу-булмау турында белешмәләрне, гомуми эш стажын да кертеп, элеккеге эш урыннары турында мәгълүматны 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 6 статьясы нигезендә һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеге булган мәгълүмат дип санауны сорыйм.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртүнең тулысынча 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләренә туры китереп башкарылуы белән килешәм.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыкның һәм аларның әлеге ризалыкта күрсәтелгән максатлар өчен һәркем файдалана алырлык булуының вакыты чикләнмәгән. Ул мин язма рәвештә аерым боерык чыгарганчы гамәлдә.

___________________________ ___________________________
(тутыру датасы) (гариза бирүче имзасы)

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Тотрыклы туризмны үстерү өлкәсендә Казан шәһәренең иң яхшы предприятиесе» номинациясендә катнашу өчен гариза-анкета**

| | |
|---|---|
| Гариза өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Җаваплы зат белән элемтә өчен белешмәләр | |
| Устав нигезендә компаниянең тулы атамасы | |
| Устав нигезендә компаниянең кыскача атамасы | |
| Юридик адресы | |
| Фактттагы адресы | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Компаниянең web-сайты адресы (булган очракта) | |
| Җитәкченең вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| 2023 елда эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алынган керем (млрд сум) | *Күрсәтергә:* 2-10<br>11-50<br>50 дән артык |
| 2023 елда персоналның уртача саны (мең кеше) | |
| Компания эшчәнлегенә кыскача характеристика | *Күрсәтергә, билге саны 1000 нән артык түгел* |
| Компания эшли торган Россия Федерациясе төбәкләре | *Санап чыгарга* |

| | |
|---|---|
| Компания 2023-2024 елларда катнашкан, тотрыклы үсеш тематикасы факторларын (ESG) комплекслы бәяләү нигезендә төзелгән индексларны, рейтингларны, рэнкингларны күрсәтергә, шулай ук аларда билгән позициясен билгеләргә | *Санап чыгарга* |

Анкетага теркәлә торган документлар җыелмасы (һәр файлны исеме белән күрсәтергә):

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан электрон өземтә;
- юридик затны теркәү турында таныклык (скан);
- салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы үтәлгән булу турында электрон белешмә[2];
- компания катнашырга ният белдергән тематик юнәлешләр буенча программа(лар) (һәр юнәлештә бер генә программа тәкъдим итәлергә мөмкин, компания сайлаган юнәлешләр саны чикләнми).

__________________________________________
Компания җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы

__________________________________________
Мөһер һәм имза

[2] Бурычлар буенча җайга салынмаган вәзгыять булган очракта, соңгы хисап чорындагы бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары нигезендә, катнашучының узган календарь ел өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына күләме катнашучы активларының баланс бәясенең 25 процентыннан артыграгын тәшкил иткән салымнар, җыемнар буенча недоимкасы, мәҗбүри түләүләр буенча башка бурычы (Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә кичектереп һәм өлешләп түләү рөхсәт ителгән, инвестиция салым кредиты бирелгән, Россия Федерациясе законнары нигезендә реструктуризацияләнгән суммалардан тыш, шулай ук Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә мөрәҗәгать итүченең әлеге суммаларны түләү буенча бурычы үтәлү һәм аларны түләттерүне өметсез дип тану турында законлы көченә кергән суд карары булган очраклардан тыш) булмау турында белешмә тапшырыла.

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы портье» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Бизәлеше, матурлыгы, дизайны | 1 |
| 2 | Тәкъдим ителгән материалны бирү эзлеклелеге | 2 |
| 3 | Темага туры килүе | 3 |
| 4 | Креативлык, иҗади якын килү | 1 |
| 5 | Вакыт регламентын үтәү | 3 |
| **Барлыгы максимум** | | **10 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы җыештыручы» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Үзенчәлекле булу | 3 |
| 2 | Урын-җирне җыештыру | 3 |
| 3 | Концепциягә туры килү | 1 |
| 4 | Видеоматериалның сыйфаты | 2 |
| 5 | Катнашучының тышкы кыяфәте | 1 |
| **Барлыгы максимум** | | **10 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
5 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Максималь баллар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Видеороликта күрсәтелгән объектларның төбәкнең социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни үзенчәлекләренә туры килүе | 1 – төбәкнең географик урынын билгеләү;<br>1 – төбәк тарихы белән таныштыру;<br>1 – төбәкнең төп истәлекле урыннары турында мәгълүмат бирү;<br>1 – төбәкнең социаль-икътисади яктан төзелешен билгеләү;<br>1 – төбәкнең мәдәни-тарихи үзенчәлекләрен күрсәтү;<br>1 – климат үзенчәлекләрен һәм сезонлылыкны билгеләү;<br>1 – төбәк объектларының социаль-икътисади үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге;<br>1 – төбәк объектларының тарихи-мәдәни үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге | 8 балл |

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Максималь баллар саны |
|---|---|---|---|
| 2 | Видеороликта тәкъдим ителгән объектларның төрлелеге | 1 – төбәктәге туризм төрләрен санап чыгу;<br>1 – объектларның төбәктәге туризм төрләренә туры килүе;<br>1 – социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни объектларга баруның сезонга бәйле булуы;<br>1 – төбәкнең туристлык мөмкинлекләре нигезендә андагы истәлекле урыннарның үзенчәлекләрен аерып күрсәтү | 4 балл |
| 3 | Видеороликта туристлык юнәлешен тәкъдим итүнең нәтиҗәлелеге | 0 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынмаган. Видеоролик нәтиҗәле түгел, сату өчен этәргеч булып тормый, кызыксыну уятмый;<br>1 – төбәкнең төп үзенчәлекләре өлешчә исәпкә алынган. Видеоролик өлешчә нәтиҗәле, сату өчен өлешчә этәргеч булып тора, бераз кызыксыну уята;<br>2 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынган. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, кызыксыну уята;<br>3 – төбәкнең төп үзенчәлекләре генә түгел, артык билгеле булмаган, әмма җәлеп итә алырлык мөмкинлеккә ия яклары да күрсәтелгән. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, зур кызыксыну уята | 6 балл |
| **Барлыгы максимум** | | | **18 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
6 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Ресторанның иң яхшы менеджеры» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Мәсьәләләрнең асылын тулысынча белү | 3 |
| 2 | Ачыклаучы сорауларга җаваплар | 2 |
| 3 | Җавапларны мисаллар белән тулыландыру | 2 |
| 4 | Килеп туган хәлдән үзенчәлекле чыгу | 2 |
| 5 | Грамоталы сөйләм | 1 |
| 6 | Гамәли бирем | 10 |
| **Барлыгы максимум** | | **20 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивале турында нигезләмәгә 7 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы официант» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| **Кызыл шәрабны декантацияләү** | | 15 балл |
| 1 | Санитария нормаларын үтәү | 3 |
| 2 | Декантация өчен эш өстәлен һәм инвентарьны әзерләү | 3 |
| 3 | Шәрабны презентацияләү | 3 |
| 4 | Декантацияләү техникасы | 3 |
| 5 | Шәрабны салу | 3 |
| **Тастымалларны төрү** | | 15 балл |
| 1 | Төрелгән тастымаллар саны | 3 |
| 2 | Тастымалларны пөхтә һәм катлаулы итеп төрү | 5 |
| 3 | Креативлык | 4 |
| 4 | Өстәмә аксессуарлар куллану | 2 |
| 5 | Санитария нормаларын үтәү | 1 |
| **Өстәлне сервировкалау** | | 25 балл |
| 1 | Официантның тышкы кыяфәте | 3 |
| 2 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| 3 | Өстәл сервировкалаганда эзлеклелекне саклау | 4 |
| 4 | Өстәлне әзерләү һәм ашъяулык җәю | 4 |
| 5 | Өстәл сервировкасының тәкъдим ителгән менюга туры килүе | 4 |
| 6 | Сервировка геометриясе | 4 |
| 7 | Өстәмә аксессуарлардан файдалануның максатка ярашлы булуы | 2 |
| 8 | Өстәлне бизәү предметларын дөрес файдалану | 2 |
| **Кунакларга хезмәт күрсәтү** | | 30 балл |
| 1 | Кунакларны чакыру. Аларны өстәл артына утырту | 3 |

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 2 | Официантның кунаклар белән аралашуы, менюны тәкъдим итү | 4 |
| 3 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү эзлеклелеген саклау | 5 |
| 4 | Әзерләнгән ризыкны табынга бирү техникасы | 5 |
| 5 | Кулланган савыт-сабаны җыештыру техникасы | 5 |
| 6 | Өстәлне десерт китерүгә әзерләү һәм аны табынга бирү | 2 |
| 7 | Менюда каралган алкогольсез коктейль һәм бармен тарафыннан әзерләнгән эчемлекләрне тәкъдим итү һәм табынга бирү техникасы | 4 |
| 8 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **Өстәл җыештыру** | | 15 балл |
| 1 | Кунакларны озату | 2 |
| 2 | Өстәлдә калган предметлар һәм ризык | 2 |
| 3 | Калган савыт-сабаны җыю техникасы | 4 |
| 4 | Өстәлне җыештыру өчен махсус җайланмалардан һәм предметлардан файдалану | 2 |
| 5 | Ашъяулыкны җыю техникасы | 3 |
| 6 | Санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү | 2 |
| **Барлыгы максимум** | | **100 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
8 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы бармен» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Тышкы кыяфәт | 0-5 |
| 2 | Чыгыш ясау өчен эш урынының әзерлеге | 0-5 |
| 3 | Коктейль әзерләү технологиясен үтәү | 0-10 |
| 4 | Катнашучының үз-үзен ышанычлы тотуы | 0-10 |
| 5 | Коктейльне табынга үзенчәлекле бирү | 0-10 |
| 6 | Коктейльне билгеләнгән вакыт эчендә әзерләү һәм презентацияләү | 0-5 |
| 7 | Коктейль әзерләгән вакытта эш урынының чисталыгы | 0-10 |
| 8 | Коктейльне бокалларга тигез салмау, шейкерда калган өлеше | 0-5 |
| 9 | Коктейль әзерләү һәм аны бирү барышында гигиена нормаларын үтәү | 0-5 |
| 10 | Коктейльне презентацияләү | 0-10 |
| 11 | Коктейльне бәяләү | 0-10 |
| **Барлыгы максимум** | | **85 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
9 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы пешекче» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Әзерләнгән ризыкның тышкы күренеше | 5 |
| 2 | Төсе | 5 |
| 3 | Тенденцияләрне үтәү | 5 |
| 4 | Текстурасы (консистенциясе) | 5 |
| 5 | Исе | 5 |
| 6 | Тәме | 20 |
| 7 | Ризыкны әзерләү идеясе һәм аны тәкъдим итү | 5 |
| 8 | Эш урынын оештыру | 5 |
| 9 | Санитария-гигиена кагыйдәләрен үтәү | 5 |
| 10 | Һөнәри алымнарга ия булу | 5 |
| 11 | Продуктларны рациональ файдалану | 5 |
| 12 | Җиһазларны дөрес куллану, хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү | 5 |
| 13 | Катнашучының тышкы кыяфәте | 5 |
| **Барлыгы максимум** | | **80 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
10 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы кондитер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Гигиена, эш урынын оештыру (mise en place), продуктны рациональ файдалану | 0-10 |
| 2 | Һөнәри яктан дөрес әзерләү, һөнәри осталык, ризыкны әзерләүнең катлаулы булуы | 0-25 |
| 3 | Презентация һәм композиция (презентация өстәле) | 0-15 |
| 4 | Әзерләнгән ризыкның тәме | 0-50 |
| **Барлыгы максимум** | | **100 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
11 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Иң яхшы сити-блогер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү**

| № т/б | Бәяләү критерие | Максималь баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Контент (темага туры килү, уникальлек, урынның/маршрутның сирәк очравы) | 50 |
| 2 | Башкару сыйфаты | 50 |
| 3 | Чит ил тамашачысына чыгу* | 10* |
| **Барлыгы максимум** | | **100 (110*) балл** |

*мәҗбүри булмаган критерий

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
12 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Яшь йолдыз. Эчке һәм читтән керү туризмы буенча иң яхшы менеджер» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Максималь баллар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Видеороликта күрсәтелгән объектларның төбәкнең социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни үзенчәлекләренә туры килүе | 1 – төбәкнең географик урынын билгеләү;<br>1 - төбәк тарихы белән таныштыру;<br>1 – төбәкнең төп истәлекле урыннары турында мәгълүмат бирү;<br>1 – төбәкнең социаль-икътисади яктан төзелешен билгеләү;<br>1 – төбәкнең мәдәни-тарихи үзенчәлекләрен күрсәтү;<br>1 – климат үзенчәлекләрен һәм сезонлылыкны билгеләү;<br>1 – төбәк объектларының социаль-икътисади үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге;<br>1 – төбәк объектларының тарихи-мәдәни үзенчәлекләргә туры килүенең дөреслеге | 8 балл |
| 2 | Видеороликта тәкъдим ителгән объектларның төрлелеге | 1 – төбәктәге туризм төрләрен санап чыгу;<br>1 – объектларның төбәктәге туризм төрләренә туры килүе; | 4 балл |

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Максималь баллар саны |
|---|---|---|---|
| | | 1 – социаль-икътисади һәм тарихи-мәдәни объектларга баруның сезонга бәйле булуы;<br>1 – төбәкнең туристлык мөмкинлекләре нигезендә андагы истәлекле урыннарның үзенчәлекләрен аерып күрсәтү | |
| 3 | Видеороликта туристлык юнәлешен тәкъдим итүнең нәтиҗәлелеге | 0 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынмаган. Видеоролик нәтиҗәле түгел, сату өчен этәргеч булып тормый, кызыксыну уятмый;<br>1 – төбәкнең төп үзенчәлекләре өлешчә исәпкә алынган. Видеоролик өлешчә нәтиҗәле, сату өчен өлешчә этәргеч булып тора, бераз кызыксыну уята;<br>2 – төбәкнең төп үзенчәлекләре исәпкә алынган. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, кызыксыну уята;<br>3 – төбәкнең төп үзенчәлекләре генә түгел, артык билгеле булмаган, әмма җәлеп итә алырлык мөмкинлеккә ия яклары да күрсәтелгән. Видеоролик нәтиҗәле, сату өчен этәргеч булып тора, зур кызыксыну уята | 3 балл |
| **Барлыгы максимум** | | | **15 балл** |

Туристлык, ресторан һәм кунакханә
индустриясе предприятиеләре
хезмәткәрләре арасында
«Кунакчыллык йолдызлары – 2024»
III төбәкара һөнәри осталык
фестивале турында нигезләмәгә
13 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестиваленең «Тотрыклы туризм өлкәсендә Казан шәһәренең иң яхшы предприятиесе» номинациясе буенча сайлап алу этабы биремен бәяләү критерийлары**

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәяләү критериен детальләштерү | Максималь баллар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Энергияне сак тоту | 0 – энергияне сак тоту принциплары эшләнмәгән;<br>1 – диод утлы лампалар;<br>1 – хәрәкәт датчиклары;<br>10 – объектны төзегәндә энергияне сак тоту материалларын куллану | 12 балл |
| 2 | Суны экономияләү | 0 – юк;<br>1 – номерларда аэраторлар урнаштырылган | 1 балл |
| 3 | Чүпне сортларга аеру | 0 – чүп сортларга аерылмый;<br>10 – эшкәртүгә җибәрү | 10 балл |
| 4 | Социаль проектлар | 0 – социаль проектларда катнашмый;<br>1 – социаль проектларда катнаша. Предприятие катнаша торган проектларны санап чыгарга (һәр проект өчен 1 балл, максимум – 20 балл) | 20 балл |
| 5 | Локаль тәэмин итүчеләр | 0 – юк;<br>1 – бар | 1 балл |
| 6 | Уңайлы мохит | 0 – юк;<br>1 – бар | 1 балл |
| **Барлыгы максимум** | | | **45 балл** |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 5 декабрендәге
5035 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру буенча экспертлар советы составы**

| | |
|---|---|
| Лодвигова Евгения Анатольевна | экспертлар советы җитәкчесе, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Санникова Дарья Александровна | экспертлар советы җитәкчесе урынбасары, «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе директоры |

Экспертлар советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Сәлмәнова Гүзәл Әсгать кызы | «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе директоры урынбасары |
| Устюжанин Андрей Владимирович | «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенең грантлы һәм конкурслы программаларны гамәлгә ашыру һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге башлыгы |
| Баһаутдинова Наилә Гомәр кызы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Идарә, икътисад һәм финанслар институты директоры (килешү буенча) |
| Гаязов Зөфәр Фәдип улы | Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты (килешү буенча) |
| Ковалева Фәридә Рәхиб кызы | «Халыкара сервис көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Прусс<br>Нэлла Матвеевна | «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Нам<br>Сония Роберт кызы | «Кулинария һәм сервис буенча халыкара мәктәп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Тимирясова<br>Асия Витальевна | «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (ИЭУП)» югары белем бирүче хосусый мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Репринцев<br>Владимир Григорьевич | Идел буе шәһәрләре ассоциациясенең башкарма директоры (килешү буенча) |
| Казанцева<br>Анна Георгиевна | Чуваш Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Чуваш Республикасы Икътисади үсеш һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, Чуваш Республикасы Чабаксар шәһәренең «Туризмны үстерү үзәге» автоном коммерциягә нигезләнмәгән оешмасы рәисе, «Городские легенды» уникаль сәяхәтләр агентлыгы җитәкчесе (килешү буенча) |